СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 166 от 13.12.2022
На № __________ от ____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты турында

2014 елның 19 декабрендә кабул ителгән 281 номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Россия Федерациясе Законының 44 статьясына, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын яңа редакциядә кабул итү турында” 2014 елның 19 декабрендәге 281 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Саба муниципаль районында ачык тыңлаулар турында нигезләмә проекты хакында” 2006 елның 21 ноябрендәге 94 номерлы карары белән расланган тәртиптә, 2023 елның 16 гыйнварында 10:00 сәгатьтә ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров ур., 52 йорт адресы буенча урнашкан муниципаль район Башкарма комитеты бинасының актлар залында ачык тыңлаулар уздырырга.
3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның алар турында фикер алышуда катнашу тәртибен расларга.
4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына 2023 елның 13 гыйнварына кадәр җибәрергә.
5. Түбәндәгеләрне бастырып чыгарырга:

– “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проектын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында ;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашу тәртибен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектының ачык тыңлауларын уздыру тәртибен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы А.И. Миңнекаевка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Советының 2022 елның
13 декабрендәге 166 номерлы
карары белән
РАСЛАНГАН

# Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты

**1.** Уставның 6 статьясының 1 пунктының 35 пунктчасында “, ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыр” сүзләрен төшереп калдырырга;

**2.** Уставның 6 статьясының 2 пунктындагы 23 пунктчасында “, ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыру” сүзләрен төшереп калдырырга;

**3.** 11 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәттән азат ителгәндә муниципаль хезмәткәргә эштән азат ителгән көнгә билгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча тиешле еллар эшләгән өчен аның айлык акчалата түләве биш мәртәбә арттырыла, муниципаль хезмәт стажы булганда, тиешле елда тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен аның дәвамлылыгы түбәндәгечә исәпләп чыгарыла:

- 2022 елда 18 ел,
- 2023 елда 18 ел 6 ай,
- 2024 елда 19 ел,
- 2025 елда 19 ел 6 ай,
- 2026 һәм аннан соңгы елларда - 20 ел һәм муниципаль хезмәтнең аннан соңгы һәр тулы елы өчен - өстәмә рәвештә 0,5 акчалата түләү, әмма муниципаль хезмәткәрнең акчалата эчтәлегенең ун күләменнән артмый (алга таба - пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бүләкләү).

Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат иткән көнгә билгеләнә.

Әлеге статьяның максатлары өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, картлык буенча хезмәт пенсиясе алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч яисә "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләгәндә, муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле эштән азат ителүдән тыш, һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда, муниципаль хезмәттән азат ителү аңлашыла.

**4.** 19 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Ачык тыңлаулар яисә җәмәгать фикер алышулары уздыру турында мәгълүмат, аларның уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, шулай ук ачык тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, ачык тыңлаулар яисә җәмәгать фикер алышулары үткәрелә торган көнгә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми

сайтында, шулай ук ”Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш;

**5.** 19 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7. Ачык тыңлаулар үткәрү һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты турында мәгълүмат басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән район халкы район Башлыгына ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты яки мәсьәләсе буенча, шул исәптән “Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрергә хокуклы.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җибәрү ачык тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Район башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра һәм аларны ачык тыңлауларда катнашучыларга җиткерә.»;

**6.** 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында ачык тыңлаулар яисә җәмәгать тыңлаулары узган көннән алып 5 календарь көннән дә соңга калмыйча бастырылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.”

**7.** 45 статьяның 1 пунктындагы 3 пунктчасының тугызынчы абзацында “, ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыра” сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Советының2022 елның
13 декабрендәге 166 номерлы
карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның алар турында фикер алышуда катнашу тәртибе.**

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына тәкъдимнәр, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына, 422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г.Закиров ур., 52 йорт, 315 бүлмә адресы буенча язма формада Саба муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгына кертелә.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында басылып чыккан көннән алып кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г. Закиров урамы, 5 йорт, 315 бүлмә, шәхсән яки почта аша (конвертта “Устав турында фикер алышу” тамгасы белән).